**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2023 Балык Бистәсе штп. № 27пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.05.2021 №111пи карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы «Реклама турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 16 апрелендәге 106-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 25.05.2021 ел, №111пи карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (29.12.2021 ел, №291пи, 27.06.2022 ел, №133пи редакциясендә ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.8.2 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәте, 38-ФЗ номерлы 19 статьяның 5.1, 5.6, 5.7 өлешләрендә кулланыла торган очракта 5 өлештә билгеләнгән таләпләрне бозу».

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 маендагы 111пи номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (29.12.2021 №291пи, 27.06.2022 №133пи редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган җир кишәрлегендә ярдәмче файдаланудагы биналар һәм корылмалар төзү;».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д.Н. Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов